**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№445**
**04.02.2020**

Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3251 номерлы, 2017 елның 3 маендагы 2748 номерлы, 2017 елның 11 июлендәге 4092 номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 7675 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 3045 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.9 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон («Российская газета», № 273, 04.12.2019)»;

2) 1.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.10. Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта һәм өстенлекле урнашу хокукы федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм закон нигезендәге норматив-хокукый актлар белән билгеләнә.»;

3) 2.5 пунктның икенче баганасында:

- 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гамәлдәге федераль яки региональ законнар нигезендә оешмада чираттан тыш, беренче чиратта һәм өстенлекле урын бирүгә хокукын (ташламасын) раслаучы документ (булган очракта);»;

- түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Оешмага өстенлекле кабул итү өчен:

- оешмага кабул ителгән өлкәнрәк баланың туу турында таныклыгы;
- оешмага исәпкә куелган баланың туу турында таныклыгы;
- ата-аналарның оешма белән килешүе;
- гаилә составы турында белешмә (гаилә составы һәм прописка турында йорт кенәгәсеннән өземтә;»;

4) 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен дәүләт җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы, гариза бирүче тапшырырга тиешле норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | баланың туу турында таныклыгы;<br>ташламаларны раслаучы документлар:<br>күп балалы гаилә балалары;<br>Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарның балалары; инвалид балалар;<br>ата-ананың берсе булса да инвалид булган гаиләләр | |

5) 3.6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. 1 апрельдән 31 августка кадәр юлланган баланы оешмага кабул итү «Килешү төзү» статусы бирелгән көннән башлап 90 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Калган чорда юлланган баланы Оешмага кабул итү «Килешү төзү» статусын алганнан соң 30 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р. М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе<br>вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев